Лубян авыл җирлеге Советы

КАРАР

15.06.2022 №10

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турындагы кодексы, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә Лубян авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында кушып бирелгән нигезләмәне расларга.
2. Лубян авыл җирлеге Советының «Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 8 апрелендэге 12 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Г.Ф.Тежикова